# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Минималь хезмәт хакы турында" ("Минималь хезмәт хакы турында" Татарстан Республикасы Законын үзгәртү хакында" 1994 елның 8 февралендәге Татарстан Республикасы Законы тарафыннан кертелгән үзгәрешләр белән) 1994 елның 20 октябрендәге Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

хакында

<u>1 статья.</u> 4 статьяны 6 статья дип санарга.

<u>2 статья.</u> Законга түбәндәге эчтәлектәге 4 статья өстәргә:

"4 статья. Законны бозган өчен җаваплылык

"Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында" Татарстан Республикасы Законы билгеләгән күләмнән кимрәк хезмәт хакы түләгән өчен эш бирүчеләргә хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр административ штраф салына.

Административ җәза бирелгәннән соң бер ел дәвамында кабат шундый ук гамәлләр кылган өчен хезмәт өчен түләүнең егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына".

<u>3 статья.</u> Законга түбәндәге эчтәлектәге 5 статья өстәргә:

"5 статья. Административ хокук бозуларны караучы органнар

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр хокук бозуларны кылган урындагы хөкем органнары тарафыннан карала.

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар кылган өчен салынган штраф тәртип бозучы тарафыннан халыкны җәмгыяви яклауның җирле (шәһәр, район) фондына кертелә".

4 статья. Әлеге Закон 1994 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,

1994 елның 8 июне